РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
КИРТЕЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КИРТӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

422387 с. Киртели, ул. Гагарина, 14

422370 Киртәле авылы, Гагарин урамы, 14

тел. (84373) 5-20-28 факс 52-0-28, e-mail: Krt.Tet@tatar.ru
ОГРН 1021606557048, ИНН/КПП 1638001600/163801001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**26 .11. 2024** **№ 49-2**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Киртәле авыл җирлегенең 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына бюджеты турында (1 укылыш)**

1 Статья

1. 2025 елга Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Киртәле авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:
1) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Киртәле авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 1958,60 мең сум күләмендә;
2) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Киртәле авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 1958,60 мең сум күләмендә;
3) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Киртәле авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 0,00 мең сум күләмендә.
2. 2026 елга һәм 2027 елга Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Киртәле авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга.:
1) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Киртәле авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 2026 елга 2034,10 мең сум һәм 2027 елга 2110,00 мең сум күләмендә;
2) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Киртәле авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2026 елга 2034,10 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 50,90 мең сум күләмендә, һәм 2027 елга 2110,00 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 105,50 мең сум күләмендә;
3) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Киртәле авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 2026 елга 0,00 мең сум һәм 2027 елга 0,00 мең сум күләмендә.
3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Киртәле авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2 Статья

1. 2026 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Киртәле авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген 0,00 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Киртәле авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген нульле Россия Федерациясе валютасында расларга.

2. 2027 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Киртәле авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген 0,00 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Киртәле авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген нульле Россия Федерациясе валютасында

расларга.
3. 2028 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Киртәле авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген 0,00 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Киртәле авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген нульле Россия Федерациясе валютасында расларга.

3 Статья

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Киртәле авыл җирлеге бюджетында 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына фаразлана торган керемнәр күләмнәрен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4 Статья

1.Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Киртәле авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.
2.Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Киртәле авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга
3.Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Киртәле авыл җирлеге бюджетының гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2025 елга 0,00 мең сум, 2026 елга 0,00 мең сум һәм 2027 елга 0,00 мең сум күләмендә расларга.

5 Статья

Субсидияләр юридик затларга (дәүләт (муниципаль учреждениеләргә), индивидуаль эшкуарларга һәм физик затларга – товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерүчеләргә субсидияләрдән тыш, Тәтеш муниципаль районының Киртәле авыл җирлеге Советы карары белән билгеләнгән тәртиптә бирелә.

6 Статья

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга Тәтеш муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле башка бюджетара трансфертлар күләмен муниципаль контрольне гамәлгә ашыру өлешендә төзелгән килешүләр нигезендә расларга:

2025 елга 1,00 мең сум күләмендә;
2026 елга 1,00 мең сум күләмендә;
2027 елга 1,00 мең сум күләмендә.

7 Статья

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Киртәле авыл җирлеге бюджетында Тәтеш муниципаль районы бюджетыннан алынучыларны исәпкә алырга
1) җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр:
2025 елга - 1490,20 мең сум күләмендә;
2026 елга-1559,80 мең сум күләмендә;
2027 елга-1628,30 мең сум күләмендә.
2) территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекчәләре булмаган җирле үзидарә органнарына беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыруга РФ вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләр:
2025 елга-0,00 мең сум күләмендә;
2026 елга-0,00 мең сум күләмендә;
2027 елга-0,00 мең сум күләмендә.

8 Статья
Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Киртәле авыл җирлеге җирле үзидарә органнары 2025 елда муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.
9 Статья
Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Киртәле авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.
10 Статья
Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
11 Статья
Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).
12 Статья
Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Җитәкче** **Поселкина С.В.**